КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 6 декабрь г.Казань № 1116

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту һәм Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен кертү буенча проект офисын төзү турында» 2016 ел, 4 май, 278 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту һәм Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен кертү буенча проект офисы составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту һәм Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен кертү буенча проект офисын төзү турында» 2016 ел, 4 май, 278 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 27 июль, 511 нче; 2016 ел, 16 декабрь, 936 нчы; 2017 ел, 8 июнь, 363 нче; 2017 ел, 16 август, 584 нче; 2018 ел, 17 гыйнвар, 15 нче; 2018 ел, 25 июнь, 512 нче; 2019 ел, 22 май, 428 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту һәм Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен кертү буенча проект офисы составына (алга таба – проект офисы составы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

проект офисы составыннан М.Г.Әхмәтовны, Т.Д.Нагумановны, А.К.Хамаевны, Р.А.Шәйхетдиновны чыгарырга;

проект офисы составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры Фәнил Әнвәр улы Әһлиуллинны;

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Азат улы Җәббаровны;

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Ринат улы Хәйруллинны.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин